**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**17 ноябрь 2021 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 17 ноябрендә 9.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2022 елда 650 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; 90 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- кыш коне Чураш авылы юлларын кардан чистарту( эшлэнгэн эшкэ тулэу)
- Чураш авылы зиратына мотопила алу;
- Чураш авылларында урам яктырткычларын ремонтлау һәм урнаштыру;;
-Чураш авылында урнашкан паркка тозелеш материаллары алу
- балаларга уен майдэнчыгы алу;
-биек ускэн агачларны хэм куакларны кису,чистарту
- район газетасында некрологларны хэм юбилярларны котлауны бастырып чыгару;
- пожар куркынычсызлыгы кысаларында , пожарный колонка алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 148 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 75 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 75 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2022 елда 650 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы I төркем инвалидлардан; 90 яшьтән өлкәнрәк булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- кыш коне Чураш авылы юлларын кардан чистарту( эшлэнгэн эшкэ тулэу)
- Чураш авылы зиратына мотопила алу;
- Чураш авылларында урам яктырткычларын ремонтлау һәм урнаштыру;;
-Чураш авылында урнашкан паркка тозелеш материаллары алу
- балаларга уен майдэнчыгы алу;
-биек ускэн агачларны хэм куакларны кису,чистарту
- район газетасында некрологларны хэм юбилярларны котлауны
- пожар куркынычсызлыгы кысаларында , пожарный колонка алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль

районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева